ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 154-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.Ф. Аитов, Р.Р. Гайзатуллин, А.Ю. Егоров, Р.Р. Йосыпов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 154-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 560-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Н.Ф.Аитов,
Р.Р. Гайзатуллин,
А.Ю. Егоров,
Р.Р.Йосыпов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 56 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$11^1$) җиңел таксилар региональ реестрына белешмәләр кертелергә мөмкин булган транспорт чараларының гомуми санын билгеләү тәртибен, җиңел таксилар региональ реестрына Федераль законның 9 статьясындагы 9 өлешенең 2 пункты таләпләренә туры килүче транспорт чарасы турында белешмәләр кертү хакындагы хәбәрнамәләрне исәпкә алу һәм карау тәртибен билгеләү;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 580-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

580-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып, җиңел таксиларны локальләштерүгә таләпләр 2033 елның 1 гыйнварына кадәр физик затлар милек хокукында алты айдан артыграк ия булган һәм, транспорт чаралары җиңел таксилар региональ реестрына белешмәләр кертелгән транспорт чараларының гомуми санынннан 25 процент тәшкил итүче квотага туры килгән очракта физик затлар тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртү өчен файдаланылачак транспорт чараларына кагылмый. Җиңел таксилар региональ реестрына белешмәләр кертелергә мөмкин булган транспорт чараларының гомуми санын билгеләү тәртибе, транспорт чарасы турында белешмәләр кертү хакындагы хәбәрнамәләрне исәпкә алу һәм карау тәртибе Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

580-ФЗ номерлы Федераль законның әлеге нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен билгели торган 3 статьясына үзгәреш кертү һәм әлеге органга җиңел таксилар региональ реестрына белешмәләр кертелергә мөмкин булган транспорт чараларының гомуми санын билгеләү тәртибен, җиңел таксилар региональ реестрына Федераль законның 9 статьясындагы 9 өлешенең 2 пункты таләпләренә туры килүче транспорт чарасы турында белешмәләр кертү хакындагы хәбәрнамәләрне исәпкә алу һәм карау тәртибен билгеләү вәкаләтен беркетү тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру

турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Федераль законның 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 маендагы 116-ФЗ номерлы Федераль законның үз көченә керү датасына – 2026 елның 1 мартыннан – туры китерү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2024 елның 20 маендагы 339 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.